# Беләгеңдә – көч, йөрәгеңдә дәрт булганда...

**Татарстанда 920 мең кеше пенсия яшендә. Аларның 23,8 проценты эшләвен дәвам итә. Ә эшкә чыгарга теләге булганнар күпме? Әйе, гомер буе тир түккән хезмәт урыныннан китү алай ансат түгел. Өлкәннәребез эштән тәм таба белә, кул кушырып тик утыруны өнәми. Беләгеңдә – көч, йөрәгеңдә дәрт булган кеше нишләп өйдә утырсын соң?!**




Өлкәннәр эштән курыкмый

## Әби-бабайга яңа һөнәр

Менә шуларны күздә тотып, Россия күләмендә пенсия яшендәгеләрне укыту, соңрак эшкә урнашырга ярдәм итү кебек чаралар күрелә. Максаты бер булса да, төбәкләр бу эшкә үзенчә якын килә. Татарстанда Президент Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча, 2012 елдан “Интернет – озын гомер” проекты гамәлгә керде. Пенсионерларны компьютер, интернет серләренә өйрәтү традициягә әйләнде. Озак еллар җәмәгать эшләрендә актив катнашкан, бүген Россия пенсионерлар берлеге иҗтимагый оешмасының төбәк бүлеген җитәкләгән Любовь Мишина һәр чыгышында озак яшәү һәм сәламәтлекне яхшырту өчен өч нәрсә мөһим булуын гел искәртеп килә: укып хәтерне ныгытып тору, физик күнегүләр белән тәнне язу, аралашып, кәефне күтәрү. Менә шулар, әллә ни катлаулы да түгел кебек.

Быелдан башлап пенсия яшендәге яки пенсиягә якынлашып килүче абый-апаларны, әби-бабайларны компьютер серләреннән тыш, бүтән һөнәрләргә дә укытырга керешәчәкләр. “Нинди һөнәрләргә укытып булачагын җентекләп уйландык, – ди ТР хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова. – Ул һөнәрләр өлкәннәргә кыенлыклар тудырмасын, кызыксыну да уятсын, шул ук вакытта хезмәт базарында ихтыяҗ да булсын”.

Пенсионерлар эшсез калган гражданнарга өстәмә һөнәри белем бирү программасы буенча укытыла. Әлеге эшне быел Казандагы һәм Чаллыдагы мәшгульлек үзәкләре белән берлектә тормышка ашырмакчылар. Ә һөнәрләргә килсәк, алар төрле – ЭВМ операторы, хисапчы, лифтер, җылыту системасы операторы, тракторчы, сакчы, аш-су остасы-кондитер, тегүче, фотограф, чәчтараш, маникюрчы, компьютер дизайнеры, флорист, ландшафт дизайнеры, риэлтор, урта һөнәри белем бирү оешмаларында эшкә өйрәтү остасы, хезмәтне саклау буенча белгеч, архив эшчесе, иминият агенты, медиатор һәм башкалар. “Яшьләр җитезлек, креативлык белән алдырса, бар шундый һөнәрләр: анда өлкәннәрнең тәҗрибәсе, сабырлыгы бик кирәк”, – дип ассызыклый Эльмира Зарипова. Пенсия яшендәгеләрне әнә шул өлкәләргә җәлеп итү күздә тотыла да.

## Алар битараф түгел

Казанда Өлкәннәр көне алдыннан зурлап уздырылган “Актив озак яшәү” күргәзмәсендә дә олылар үзләренең бернәрсәгә дә битараф түгеллеген күрсәтте. Анда Казаннан тыш, Яшел Үзән, Биектау, Лаеш, Питрәч һәм тагын башка бик күп районнардан килүчеләрне очратырга мөмкин иде. “Казан ярминкәсе” күргәзмәләр залында оештырылган әлеге чарада сәламәтлек саклау темасына лекцияләр тыңладылар, табибларда тикшеренү үттеләр. Юристка, пенсия фонды вәкиленә сорау бирүчеләр дә шактый булды. Эшкуарлар шунда ук җиләк-җимеш үсентеләре, куаклар, чәчәкләр тәкъдим итте. Ул да өлкәннәр күңеленә хуш килде. Чараның беренче көнендә оешмалар 15 меңнән артык буш вакансия белән таныштырды.

Ни бар икән биредә дип берничә минутка гына кергән Фәимә апа Яшәрова күргәзмәдә озак тоткарланды. Ачык күңелле апа булып чыкты ул, рәхмәт яугыры. 67 яшьлек Фәимә апа 40 елдан артык җәмәгать туклануы өлкәсендә эшли икән, 20 ел технолог вазыйфасында. Фәимә апаның да өлкәннәр өчен оештырылучы курсларда укырга теләге бик зур. “Компьютерны беләм, ләкин тагын да яхшырак өйрәнәсе килә, бакчам матур, тагын да ныграк зәвык белән бизисе килә, шуңа күрә компьютер, ландшафт дизайнерына укысаң бер дә комачауламас иде”, – ди ул. Аның белән укудан тыш, эшкә мөнәсәбәт һәм мөмкинлекләр турында да сөйләшеп алдык. Тормышка, яшәүгә күңел сүрелмәсен өчен һәркемнең шөгыле булырга тиеш, дип саный Фәимә апа. “Өйдәге бертөрлелек туйдыра, тик утырганда эч поша башлый, әле бер җирең авырта кебек, әле икенче төшең... Ничә яшьтә булсаң да, хәрәкәт кирәк, – ди ул. – Эшкә барганда кеше янына чыгасың бит, матур күлмәк кияргә тырышасың, чәчеңне дә, тырнагыңны да карыйсың. Байтак кеше әле эшләрдәй яшьтә пенсиягә озатыла, бик күпләр моны авыр кичерә. Алар өчен дә бу курслар бик әйбәт булачак. Хезмәтем буенча чит илләрдә шактый йөрдем. Аларда үрнәк алырлык әйберләр аз түгел. Германиядә, Австриядә өлкәннәр өчен махсус эш урыннары бар. Карт-карчыклар күңелләренә якын, булдыра алырдай шөгыль белән мәшгуль. Кемдер чигә, кемдер тегә, бакчада эшли, җәмгыять өчен файдалы эш башкара һәм үзен бик кирәк итеп тоя. Аларны хезмәт урынына балалары, оныклары иртән китереп куя, кич белән алып кайта”.

Әйе, әби-бабай өчен үзара аралашу мөмкинлеге дә бит әле бу. Фәимә апа пенсиягә чыгып ял итәм дип, эштән китәргә әллә ничә талпынып караган, җитәкчелек җибәрми икән. Кайда да тәҗрибәле остаз кирәк шул.

“Пенсиягә чыкканчы 35 ел бер оешмада эшләдем, 55 яшь тулып ике ай үткәч, китәргә мәҗбүр булдым. Аннары да тик тормадым, эшләдем, “балалар бакчасы”нда, оныкларымны караштым, хәзер кайсы бакчага, кайсы мәктәпкә таралды”, – ди күңелгә яраклы берәр эш таба алмам микән дип күргәзмәгә килгән Хәтирә апа Имамиева. Аңа тулы эш көне кирәкми, ирекле графикка кызыга.

## Остазларны сайлыйлар

Күргәзмә кысаларында 30га якын оешма эш тәкъдим итте. Хезмәт урыннары белән таныштыручы белгечләр пенсионерлардан да баш тартмый. Казандагы Тынычлык бистәсендә урнашкан 3нче поликлиникага, мәсәлән, участок терапевтлары җитми. Берәү генә дә түгел, өч хезмәткәр кирәк. Поликлиника җитәкчелеге бу хакта мәшгульлек үзәкләренә дә хәбәр салган. Алар аша да белгечләр көтәләр. Терапевтларның айлык уртача хезмәт хакы – 25 мең сум. “Шулай килеп чыкты инде, пенсия яшендәге хезмәткәрләр берьюлы китеп барды, – ди поликлиниканың кадрлар бүлеге җитәкчесе Татьяна Сираҗиева. – Без пенсия яшендәгеләрне дүрт куллап алырга риза, үз эшләрен яхшы беләләр, җаваплы карыйлар. Алардан халык та зарланмый”.

Ә Казан авиация-техник көллиятенә укытучылар да, производство базасында һөнәргә өйрәтү өчен остазлар да кирәк. Остазларның белемле булуы гына аз, яшь буынны эшкә өйрәтү буенча тәҗрибәсе дә булырга тиеш. Яшьләр белән эшләүне теләсә кемгә ышанып тапшырырга да ярамый, шуңа күрә хезмәткәрне алдан әнә күзеннән тикшергәндәй барлыйлар. Күргәзмәгә килгән өлкәннәр арасыннан бу һөнәрләр белән кызыксынучылар булган. “Иртәнге якта гына да 15 кеше сорашты. Аларның яртысы диярлек пенсионерлар иде”, – ди көллиятнең кадрлар белән эшләү буенча хезмәткәре Любовь Обрезкова.



Хәрәкәттә – бәрәкәт шул

Пенсионер, элеккеге педагог Анатолий Ефименко эш тәкъдим итүче оешмаларның адресларын, телефон номерларын җыеп йөри. “Студентларым өчен, – дип аңлатты ул бу гамәлен. – Берничә ел инде шулай. Гадәткә әйләнде. Студентларым белән әле дә аралашып торабыз, алар укыйлар да, эшлиләр дә, мөстәкыйльләр, үз көннәрен үзләре күрәселәре килә. Ә нигә, начар түгел бит?!”

## Пенсионерларны да көтеп калалар

Районнарда, бигрәк тә шәһәр җирендә берсеннән-берсе колачлырак супермаркетлар төзелә. Ул биналарны хезмәткәрләр белән тәэмин итеп бетерү шулай ук җиңел түгел. Директордан алып йөк ташучыга кадәр кирәк. Зур сәүдә челтәрләрендә сатучы-кассирларга, товар белән тәэмин итүчеләргә кытлык икән. Кабул иткәндә кешенең яшенә карамыйлар, авырмасын һәм эшләргә теләге булсын. Төп таләп әнә шул. “Кайбер 60 яшьлек апалар 40 яшьлек кебек күренәләр, эшкә дә җитез булалар. 40та ук олыгайган, эшкә күңеле сүрелгәннәрне дә очратасың”, – ди кибетләр челтәре хезмәткәре Юлия Иванова. Сәүдә үзәкләренә урнашучыларны һөнәргә эш барышында өйрәтәләр. Ә кызыксындыруга килгәндә, эшкә рәсми рәвештә алалар, хезмәт хакын ай саен вакытында түлиләр, графикны сайлау мөмкинлеге бар: 5 көн эшләп, ике көн ял итәргә һәм ике көн эшләп, 2 көн ял итәргә була. Үзен яхшы яктан күрсәткәннәрне, кыскасы, бик уңганнарны карьера үсеше көтә.

“Казанкомпрессормаш” берләшмәсендә зур тәҗрибәле, электр, газ белән эретеп ябыштыручыларны көтәләр. Монда да иң әүвәл таныклыктан бигрәк кешенең эшенә карыйлар. Заводта бу һөнәр ияләренең хезмәте 40-45 мең сум белән бәяләнә. Премияләр каралган. Хезмәт хакы түләүдә тоткарлыклар юк. Кыскартуга эләкмәмме дип борчыласы да түгел, киресенчә, штатны зурайталар.

– Күңел картаймый икән ул, балакай, әллә ниләр майтарырга тели, – ди 72 яшьлек Оркыя апа Дәүлиева. – Балаларга булышасы килә, акчалары җитми. Өй янымдарак берәр эш булмас микән дип килгән идем монда. Курсларда да укыталар икән...

Оркыя апа, Фәимә апа, Хәтирә апа кебек җиңел сөякле, эшлим әле мин, дип атлыгып торган өлкәннәребезнең теләкләре тизрәк тормышка ашсын иде. Хыял-омтылышлар булу үзе яшәү бит инде ул. Өлкәннәр көне белән котлыйбыз! Күңелегез беркайчан картаюны белмәсен!

**Фәния АРСЛАНОВА**